# ӘГЪЛӘМИСИНА

*(Документаль бәян)*

## Тоткан юлыбыз – шагыйрьнең туган төбәгенә

Көннәр яна-сүнә тора
Утлар сыман.
Яна-сүнә, ә мин иртән
Филүс[1] белән юлга чыгам.
Артта калды Казан: без менә
Башны куеп тәрәзә җегенә,
Карап барабыз төнге йортларга,
Берән-сәрән янган утларга.
Утлар-көннәр артта калалар,
Күзнең явын алып яналар.
Юл читенә басып, юкәләр
Артка таба йөгереп үтәләр.
Күз кыса да кача утларым,
Сәфәреңдә эше юк аның.
Табигатьнең бар үз мәгънәсе –
Көзге муллык теле һәммәсе.
Ә соң нәрсә җитми кешегә –
Күченә дә һаман күченә…
Сәфәрнең дә бар үз мәгънәсе –
Нидер эзли…
Бәхет теле җирнең бәндәсе.
Без бармыйбыз җиргә сер сөйләп,
Әйтерсең лә бара табигать, –
Табигатьнең без бер кисәге,
Утлар – көннәр…
Гомер исәбе.
Мөдәрриснең авылын күрү –
Юлчыларның бүген исәбе[2].

Шулай бара торгач, көн яктырды, утлар сүнде, без Чаллыда эшне төгәлләдек, юлны дәвам иткәндә, кояш инде кичкә авышкан иде. Шуннан соң без Зәй ягына юл

---

[1] *Филүс Хисаметдинов* – ветеринария фәннәре докторы, шагыйрь.

[2] Бу шигырь М. Әгъләмовка ияреп язылды *(авт. искәр.)*.

тоттык. Машина элдертә генә, ә руль артында – мәхәббәт җырчысы, күп санлы җырлар иясе Филүс Хисаметдинов. Аны бу тирәдә, юк, бу тирәдә генә түгел, ә бөтен Татарстанда күп кеше белә. Бигрәк тә республикабызның танылган баш ветеринария табибы буларак беләләр аны. Ә менә Чаллы кош фабрикасында аны көтеп алалар. Ул килүгә, биредә белгечләрнең аңа күптөрле сораулары тупланган була. Кош фабрикасында ул кичә булган иде, бүген дә сораулар, хәл итәсе проблемалар шактый җыелган. Башта ул шунда тукталды, кичекмәстән хәл итәргә тиешле чараларны хәл итеп, белгечләргә кирәкле күрсәтмәләрне биреп, ярдәм күрсәтергә дә өлгерде ул.

Үзе ветеринария фәннәре докторы, профессор булса да, бүген Филүс Хисаметдиновны башка нәрсә борчый, ул ветеринариядән шактый ерак хыял белән яна. Халык шагыйре Мөдәррис Әгъләмовның эзләреннән аның туган төбәгенә ашыга. Төп теләге – Мөдәрриснең исемен мәңгеләштерү – ул укыган Түбән Биш авылы мәктәбендә аның музеен ачу…

Яр Чаллыда без Мөдәрриснең Рәсимә апасы белән очрашырга, аның фикерләрен белергә, теләген ачыкларга уйлаган һәм сөйләшеп тә куйган идек. Ләкин син дигәнчә генә буламыни ул… Үч иткәндәй, апасы бүген безнең теләкне канәгатьләндерә алмады.

– Гафу итегез, көтмәгәндә бик нык авырып киттем бит, – диде ул, – туктаусыз ютәллим, температура… Чиллә вакытында каян эләккәндер… Сезгә йоктырырмын дип куркам, – диде дә сүзен дәвам итте: – Соңрак, бераз хәл алгач килсәгез әйбәт булыр иде. Яисә үзем сезнең янга – Казанга сугылырмын. Озакламый Мөдәрриснең туган көне җитә, аны Язучылар берлегенең Тукай клубында билгеләп үтәргә җыеналар… Шунда очрашырбыз. Дөрес, бу әле октябрь аенда гына булачак. Бәлки, аңа кадәр дә очрашырбыз, Алла боерса…

Шулай итеп, бу килүдә без Мөдәрриснең апасы Рәсимә ханым белән утырып, иркенләп сөйләшә алмадык. Югыйсә бик тә сөйләшәсе, фикер уртаклашасы килгән иде аның белән. Апасы турында бик матур шигырьләр язды бит шагыйрь. Аның бигрәк тә «Апам» дигән шигыре җылы тәэсир уяткан иде миндә.

Балалары да бар, ә ул һаман
Бала итә,
Ташлап эшләрен,

Иң беренче булып килеп җитә:
— Нәрсә булды, энем, нишләдең?!
Җомга көннәрендә хәер биреп
Юрата да күргән төшләрен,
Тыны-өне бетеп килеп керә:
— Нәрсә булды тагын, нишләдең?!

Шигырьнең әлеге юлларында шагыйрь яраткан апасының аның турында — авыру энесе турында ничек кайгыртуын, ничек борчылуын җылы итеп тасвирлый.

Табибларның яңа авыру табып,
Серен эзләп, төбенә төшкәнен.
Ишетә дә миндә эзен таба:
— Кайчан булды, энем, нишләдең?
Уйламас та, аңламас та, ахры,
Нәрсә белән кайный бу башың?
Яңа дару чыкса уйлап сөенә
Минем өчен кирәк булганын.

* * *

Минем иртә януымнан курка,
Ахырларын беләм уенның.
...Мин үлгәч тә теләр агачларның
Мине сагынып яфрак яруын.

...Чаллыны чыккач, Зәйгә таба — Мөдәрриснең туган авылы Биш Субашына таба юл тоттык.

Юлыбызның башы шулай уңышсыз гына башлангангa, Филүс Фазыл улы бераз борчылып та алды. Әмма нишлисең бит, барысы да син уйлаганча гына булмый шул... Юл юл инде ул, анда көтелмәгән хәлләр, син уйламаган мизгелләр аз булмый.

— Ярый ла, алдагы очрашулар уңай барса, бүген хәл итеп булса... — диде ул, уйга калып. — Иң беренче шуны ачыкларга кирәк: Мөдәррис Әгъләмов укыган Түбән Биш авылы мәктәбендә аның музее чынлап та бар микән? Бар диючеләр булды булуын, әмма: «Юк, нинди музей булсын ул?» — диючеләр дә очрады. Булса, ниндирәк музей икән ул? Башта шуны ачыкларга кирәк.

— Авылда бит Мөдәрриснең яшьтиләре, туганнары да бар. Бәлки, башта аларга кереп, танышып чыгарбыз, — дидем мин.

— Дөрес әйтәсең, — диде Филүс, мине куәтләп. — Шулай эшлибез дә аны. Авылда Мөдәрриснең якын туганы Әбүзәр абый янында булырга кирәк безгә. Мөдәрриснең

әнисе Әминә белән Әбүзәрнең бабасы — бертуганнар. Ул Зәй районының Мөдәррис дөньяга килгән менә шушы Биш Субашы авылында яши. Ә Мөдәррис укыган мәктәп күрше Түбән Биш авылында. Ул мәктәпне исә Әбүзәр бик яхшы белә диделәр…

Филүс, юлга чыкканчы ук, Мөдәррис турында шактый мәгълүмат туплап өлгергән иде инде. Мин, аңа карап, тагын да соклана төштем: кызыксынучан галим… Язучыларга, җырчыларга, сәнгать вәкилләренә һәрчак ярдәм кулын суза… Вакытын да, акчасын да, башкасын да кызганмый. Үзе, инде әйткәнемчә, ветеринария фәннәре докторы булса да, сәнгать, әдәбият белән кызыксына. Үзе дә җырлар, шигырьләр яза, соңгы елларда гына да инде дүрт җыентыгын чыгарып өлгерде… Шуларның икесенә — «Күзләремдә көтәм язларны», «Язгы гөлем» исемле җыентыкларына — сүз башын үзем яздым.

Шунысы мәгълүм: Филүс, кемгәдер ияреп, шагыйрь булу хыялы белән язмый шигырьләрен.

Нигә язасың, дип сорамагыз,
Эзсез югалмаска язамын:
Туган туфрагыма кире кайтсам,
Дәвамы булып яшәр язганым, —

ди ул.

Бу шигырьнең исемен ул «Мин шагыйрь түгел» дип атаса да, аның эчтәлеге киңрәк, колачлырак һәм бу Филүснең, чынлап та, сәләте тумыштан икәнлегенә инандыра. Аның әдәбиятны яратуы, үзенең дә шигырь, җырлар язу белән мавыгуының һаман үсә баруы, аның әдипләрне, талантлы шагыйрьләрне яратуы, хөрмәт итүе, шуларга ук ярдәм итәргә, булышырга теләвенә әверелә, һәм ул татарның күренекле, халыкчан, танылган затлары белән кызыксына, аларга ярдәм итәргә һәм исемнәрен мәңгеләштереп калырга омтыла. Моннан берничә ел элек ул талантлы җырчы Таһир Якуповның иҗатын өйрәнү белән янып яшәде, аның музеен ачуда күп көч куйды, вакытын һәм ярдәмен дә кызганмады. Ә менә хәзер аның хыялы — халык шагыйре Мөдәрриснең исемен мәңгеләштерү — ул укыган мәктәпкә аның исемен бирдерү һәм шул ук мәктәптә — Түбән Биш авылы мәктәбендә шагыйрьнең музеен ачу…

Бүген юлга чыкканчы, без аның белән Мөдәрриснең Казандагы фатирында булдык (ул Социалистическая урамында), аның хәләл җефете Нәҗибә ханым Сафина

белән сөйләштек. Шагыйрьнең архивы: кульъязмалары, китаплары, шигырьләре, истәлек бүләкләре белән таныштык һәм Мөдәррис Әгъләмовның исеме мәңгеләштерелергә тиеш дигән уртак бер фикергә килдек. Киңәшле эш таркалмас, диләр…

Безнең бүгенге сәяхәт нәкъ шул фикерләшүнең, киңәшүнең дәвамы да булып тора… Менә инде без Мөдәррис Әгъләмовның туган төбәге Зәй районы территориясенә аяк бастык. Ул Кама елгасының кушылдыгы Зәй елгасы буенча урнашкан. Районның хәзер 106 мең гектардан артык авыл хуҗалыгы җирләре бар, шуның эченнән 94,8 мең гектары — сөрү җирләре. Биредә, бөртекле һәм кузаклы культуралардан тыш, шикәр чөгендере үстерәләр, димәк, шикәр эшкәртү заводы да биредә урнашкан дигән сүз. Болардан тыш, районның төп байлыгы ул — төзелеш материаллары һәм нефть.

Материаль байлыклардан тыш, шагыйрь туган район рухи байлыкларга да бай. Райондагы 56 мәктәптә 10 мең бала укый, Мөдәррис аралашып яшәгән өч дистә китапханә, 50 гә якын клуб учреждениеләре, мәдәният йортлары эшли. Шулай ук биредә күренекле шагыйрьнең тәүге шигырьләрен дөньяга чыгарган «Зәй офыклары» дигән район газетасы (ул чакта бу газета «Кызыл Зәй» исеме астында чыга) татар һәм рус телләрендә чыгып килгән.

Шагыйрьнең «Кызыл Зәй» газетасында басылган «Коймаклар» дип исемләнгән тәүге шигыре күпләрнең исендә. Әбисенә багышланган бу шигыре күтәренке рух белән язылган һәм нәкъ Мөдәррисчә төгәлләнә:

…Бәйрәмнәрдә авыл гөрләп тора,
Төрле яктан җыела кунаклар…
Кунакчыллык кайнарлыгы белән
Табаларда бии коймаклар.

Тәүге шигырьләре арасында шагыйрьнең «Балам, бәгърем» диеп исемләнгән шигыре дә игътибарга лаек:

Яман юлда йөр, дип, начар бул, дип
Үстермәгән мине әнкәем;
Байрак итеп йөртәм: «Халык юлы —
Иң изге юл», — диеп әйткәнен.

Бу шигырьнең эпиграфында шагыйрь алдан ук әнисеннән гафу үтенә кебек:

Толымыңны яраттым да,
Агарттым да, әнкәем…

Мөдәрриснең әлеге шигырьләренә кадәр элегрәк тә язылган шигыре бар. «Истәлекләр» дип аталганын автор үзе матбугатта дөнья күргән беренче шигыре дип саный:

Истәлекләр…
Истәлекләр алар күптөрле,
Истәлекләр алар күп кала —
Бу истәлек булып әнкәемнең
Чиккән сөлгеләре саклана.

Чиккән сөлгеләре саклана,
Бизәге дә аның бизәге —
Карый сыман миңа бизәктән
Әнкәемнең нурлы күзләре.

Бу шигырь дөнья күргәндә, шагыйрьгә бары тик уникенче яшь кенә була, ул 1958 елда «Кызыл Зәй» газетасында басылып чыга.

«Беренче шигыремне басмада күрү шатлыгы, әлбәттә, зур булгандыр, — дип искә ала бу турыда шагыйрь үзе, — шигырь үлчәме белән язылган, Мөдәррис Әгъләмов дип куелган… Минме икән бу, дигән горурлык тудыргандыр… ул миндә, — дип яза шагыйрь. — Әмма берничә атна үтмәде, минем бу илаһи шатлыкларым чәлпәрәмә килде… Язучы, шагыйрь Сөббух Рәфыйковның газетага килгән әдәби язмаларга күзәтүе басылып чыкты. Анда минем хакта да сүз бар, дөресрәге, минем «Истәлекләр» дигән шигырем хакында ул… Мәгънәсе шул: озак еллар әдәбияттан аерылып торуы аркасында, шигырьләрне күзәтеп бара алмаган ул (белгәнебезчә, Сөббух ага гөнаһсыз төрмәгә утыртылып, егерме елга якын югалып торган әдип), шуңа күрә бу шигырьнең кайсы шагыйрьнеке икәнен әйтә алмый. Әмма унике яшьлек мәктәп укучысының мондый шигырь яза алуына шикләнү белдерә…

Бетерде, үтерде… миннән көләләр. Берничә айлар миңгерәп йөргәч, мин терелдем… «Юк, Сөббух абый, мин әйтәм, мин яздым аны. Күршебез Миргаяз абзый әйтмешли, «докажу».

Шигырь каян башлана? Әйтә алмыйм. Ә менә шагыйрьлек шуннан башлана. Рәхмәт Сөббух агага, урыны җәннәттә булсын. Мин аңа беренче шигыремне үзем язганымны, шәт, исбат иттем шикелле».